| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ПОТАПОВО-ТУМБАРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОТАП-ТОМБАРЛЫ<br>АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2025 ел. Потап-Томбарлы авылы № 137

Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советының 13.04.2018 ел. № 56 «Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.04.2024 ел. № 226 карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советының 13.04.2018 ел. № 56 карарына кертергә «Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары

хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» (Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советының 12.09.2020 № 139, 28.09.2022 № 53, 20.12.2022 № 64, 28.03.2023 № 69, 28.06.2024 № 113, 15.11.2024 № 124 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр:

1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым оешмаларның җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме «Потап-Томбарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладı күләменә туры китереп исәпләнә, аларга бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый, ул 15 389 сум тәшкил итә.»;

3 пунктның 3 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга.;

7 пунктның 4 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үз көчен 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә.

4. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык, Совет Рәисе
Потап-Томбарлы авыл җирлеге С. А. Козлова